ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

22.03.2021

359

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 25 августындагы 1053 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе һәм Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 25 августындагы 1053 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентындагы 2 бүлекнең 2.5 пункттагы 6 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.2. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентындагы 2 бүлекнең 2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле 9 пункт белән тулыландырырга:

«9) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу».

1.3. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентындагы 3 бүлекнең 3.4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша тәкъдим итү турында запрос җибәрә:

1) аерым затның үзендә бар (булган) күчемсез мөлкәткә анық белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәт объектына теркәлгән хокуклар турында өземтә;
2) күчемсез мөлкәт объектына хокукларның күчүе турында аның белән алыш-бирешләргә һәм күчемсез мөлкәткә хокукларны турында Бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр (соңгы биш елда (Татарстан Республикасыннан читтә яшәгәндә);
3) шәхси эшмәкәр булып торучы затның керемнәре турында 3-НДФЛ формасы буенча белешмәләр;
4) физик зат керемнәре турында 2-НДФЛ формасы буенча белешмәләр;
5) йорт кенәгәсеннән күчермәләр (документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта);
6) торак урынның торак һәм гомуми мәйданын һәм бирелү датасын күрсәтеп, финанс-шәхси счет (әгәр документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән булса);
7) социаль түләүләр алу турында белешмәләр;
8) торак урыны яшәү өчен яраксыз дип тану турында карар (яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урынына ия булган гражданнар өчен).
9) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән запрослар.

2. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов